| СОВЕТ ЮРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 1** **26.11.2019ел**

**"Җир салымы турында" 2019 елның 01 октябрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Советы Карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге Россия Федерациясенең 131-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Уставы нигезендә, салым законнарына кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. "Җир салымы турында" 2019 елның 01 октябрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Советы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.2 п. 5 пп. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен билгеләнгән, **эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган** җир кишәрлекләренә карата, шулай ук дача, бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләре составында булган җир кишәрлекләренә карата 0,3%;"

1.2. 2. п. 6 пп түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- күпкатлы торак төзелеше, шәхси торак төзелеше йортларын урнаштыру өчен билгеләнгән, **эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган** җир кишәрлекләренә карата, шул исәптән, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,15%".

1.3. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 7 п.п. белән тулыландырырга:

«- **торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,3%** (торак фондына карамаган объектка һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына туры килгән) яисә (эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлегенә хокукта өлештән тыш);

1.4. 2 п. 8 пп. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«- авыл хуҗалыгы билгеләнешенә кертелгән яисә авыл хуҗалыгы файдалануы зонасы составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата 0,3%”.**

2. Гамәлдәге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз карамагыма алам.

Юртау авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Юртау авыл җирлеге рәисе И.Ю.Кадыйров